**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТЧЕРЕМШАНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Улица М.Титова, дом 7, Черемшан село, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ЧИРМЕШӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

М.Титов урамы, 7 йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс 8(84396)2-52-30 email: Cmn.Cmn2@tatar.ru

№ 81 31 гыйнвар 2023 ел

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлеге Советы
**КАРАРЫ**

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2018 елның 26 апрелендәге 123 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2018 елның 26 апрелендәге 123 номерлы карарының 1 өлешенең 3 абзацын (район Советының 2020 елның 15 октябрендәге 7 номерлы, 2022 елның

15 ноябрендәге 72 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) бәян итәргә:

1.1. Карарның 1 пунктындагы 4 абзацын бәян итәргә: «Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгече вазыйфа окладының күләме 12688 сум тәшкил итә»;

1.2. 1 нче номерлы кушымтаның III бүлегендәге 1 пунктының 6 пунктчасын бәян итәргә: «6) айлык акчалата бүләк – вазыйфа окладының 18 процентыннан артмаган күләмдә».

1.3. 6нчы кушымтаның 1 пунктын бәян итәргә: «Муниципаль хезмәткәрләргә премиядән тыш ай саен акчалата бүләк бирелә. Муниципаль хезмәткәрләрне ай саен акчалата бүләкләү вазыйфа окладының 18 процентыннан артмаган күләмдә җирле үзидарә органы җитәкчесенең карары белән билгеләнә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе Р.Т. Айбатов